**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТАБАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТӘБӘРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2025 Тәбәрле авылы № 10

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрлеавыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү методикасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлегенең башкарма комитеты карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү методикасын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Әгерҗе муниципаль районының официаль сайтында https://agryz.tatarstan.ru адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәренә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Житәкчесе Р.Р.Салимуллин

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Тәбәрле авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.08.2025 ел № 10 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү методикасы

I. Гомуми нигезләмәлә

1.1. Киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерүне уздыру методикасы (алга таба - Методика) Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10. кабул ителгән № 131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварында кабул ителгән 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән.

1.2. Методика Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә урнашкан яшел үсентеләрне рөхсәт белән алу һәм рөхсәтсез зарарлау яисә юкка чыгару очракларында компенсация рәвешендә яшелләндерү өчен муниципаль берәмлек бюджетына кертелергә тиешле түләүләрне исәпләп чыгару өчен билгеләнгән.

1.3. Методика

инвестиция проектларының әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү бүлекләрен әзерләү процессында һәм аларның Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, яшел үсентеләргә кагылышлы барлыкка килергә мөмкин булган потенциаль зыянны бәяләү буенча экологик экспертиза әзерләү барышында кулланыла;

табигать факторларын, шулай ук яшелләндерү объектларының экологик әһәмиятен исәпкә алып, рөхсәт белән яшел үсентеләрне кискән өчен түләү күләмен исәпләгәндә;

яшел үсентеләргә зыян салу (үсемлекнең үсешен туктату дәрәҗәсенә кадәр булмаганда) яисә яшел үсентеләрне юкка чыгару нәтиҗәсендә китерелгән зыянны түләгәндә;

Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә урнашкан яшел үсентеләрнең бәясен билгеләү белән бәйле башка очракларда.

1.4. Әлеге методика, урман законнарын бозып, урманнарга, шул исәптән урман үсентеләренә һәм урман үсентесе булмаган агачларга, куаклыкларга һәм лианаларга китерелгән зыян күләмен исәпләү белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

II. Киселә торган яшел үсентеләрне классификацияләү һәм идентификацияләү, аларның бәясен билгеләү

2.1. Шәһәрдәге (авылдагы) яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү өчен функциональ билгеләнешенә, урнашу урынына, милек рәвешенә һәм шәһәр территориясенең ведомство карамагына бәйсез рәвештә үсемлекләр дөньясының түбәндәге төп типлары классификациясе кулланыла:

агачлар;

куаклыклар (төркемләп һәм берәмләп утырту);

куаклардан торган коймалар;

үлән капламы (газоннар һәм табигый үлән катламы);

чәчәклекләр.

2.2.Үсемлекләргә китерелгән зыян күләмен билгеләгәндә ботаника, урман төзелеше, дендрология, геоботаника буенча, туфрак-мелиоратив, геологик һәм башка тикшеренүләр, урман һәм үсемлек кадастрлары, үсемлекләрне мониторинглау буенча мәгълүматлар, шулай ук исәпкә алынган объектның - үсемлекнең торышы турында кирәкле мәгълүмат булган паспорты файдаланыла.

Үсемлекләргә китерелгән зыянны оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә гражданнар, шәхси эшмәкәрләр оешмалар каплый.

Хокуксыз рәвештә яшел үсентеләргә китерелгән зыян китерү яки юкка чыгару очрагында өстәмә тикшеренүләр үткәрү, экспертлар җәлеп итү, документларны рәсмиләштерү чыгымнары өчен түләү экологик хокук бозуны башкарган зат акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2.3. Агач-куаклыкларга, үләнчел үсемлекләргә китерелгән зыян күләмен билгеләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

агач һәм ялгыз куаклар өчен экземплярларда яисә куаклар өчен погонлы метрларда киселә торган үсемлекләрнең саны һәм аерым үсемлекләрнең микъдарын билгеләү шактый кыен булганда;

үләнчел үсемлекләр каплаган мәйдан квадрат метрларда;

агачларның төренә, яфраклы яки ылыслы булуына карау, агачларның һәм куаклыклар, үләнчел үсемлекләрнең төре;

агач кәүсәсенең 1,3 метр биеклектәге диаметры агачның биеклеген, разрядын, 1 берәмлек агач өчен алына торган агач күләмен һәм агачның 1 куб метрын бәяләү өчен. Әгәр дә агачның берничә кәүсәсе булса һәм икенчел кәүсәсенең диаметры 8 сантиметрга җитсә, һәр кәүсә аерым агач дип санала;

бу үсемлекләрне утырту һәм карау буенча башкарылган эшләрнең бәясе һәм 1 метрга кадәр биеклектәге үсенте бәясе сумнарда;

үсемлекләрнең торышы һәм аның кыйммәте;

үсемлекләрнең деградацияләнү дәрәҗәсе (санкцияләнмәгән зарар килгәндә яки яшел үсентеләр юкка чыгарылганда гына кулланыла).

2.4. Яшел үсентеләр юкка чыгарылганда зыян күләме түбәндәге формулалар буенча билгеләнә:

| № | Яшел үсенте | Зыян күләмен исәпләү формуласы | шартлы билгеләре |
|---|---|---|---|
| | агач | Y=(C U Cv) xqxkl xкцxкцxкд Cv<br><br>=V СдЗ | С - агачның 1 төбен утырту һәм үстерү эшләренең бәясе (таб. 1)<br><br>Ц - 1 үсенте бәясе (таблица. 1) Cv - киселә торган агач күләменең бәясе<br><br>V - агачның 1 төбе өчен алына торган агач күләме;<br><br>СдЗ - 1 куб. м үзагачның бәясе;<br><br>q - алына торган агачларның төп саны;<br><br>kl - үсемлекләрнең әйләнә- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тирә мохитне саклау үзлекләрен исәпкә ала торган коэффициент (таб. 3);<br>к2 - үсемлекнең торышын исәпкә ала торган коэффициент<br>(таб. 4) ;<br>кц – үсемлекләрнең кыйммәтен исәпкә ала торган коэффициент(таб. 5);<br>кд- үсемлекнең деградация дәрәҗәсен билгеләүче коэффициент<br>(таб. 6). |
| 2 | Куаклыклар, лианалар | Y = (С+Ц) xq xkl xк2 xкц xкд | Y - зыян күләме<br>С - 1 төп яисә 1 пог. м.<br>куаклык, лианалар утырту һәм үстерү буенча эшләрнең бәясе<br>(таб. 2)<br>Ц - утырту материалы бәясе (таб 2)<br>q - киселә торган куакларның, лианаларның саны,<br>kl - үсемлекләрнең әйләнә-тирә мохитне саклау үзлекләрен исәпкә ала торган коэффициент (таб. 3)<br>к2-коэффициент, исәпкә алынучы үсемлекнең торышы(таб. 4)<br>кц - үсемлекнең кыйммәте исәпкә алына торган коэффициент (таб. 5)<br>кд - үсемлекләрнең деградацияләнү коэффициенты (6 нчы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | таблица) |
| 3 | Газоннар, чәчәклекләр | Ү = (С+Ц) xS xkl xк2 xкц xкд | Ү - зыян күләме<br>С - 1 төп яисә 1 пог.м.<br>газонны яисә чәчәклекне утырту һәм үстерү буенча эшләрнең бәясе<br>(таб. 2)<br>- утырту материалы бәясе (таб 2)<br>S- алынган (юкка чыгарылган) газон, чәчәклекнең бәясе<br>kl - үсемлекләрнең әйләнә-тирә мохитне саклау үзлекләрен исәпкә ала торган коэффициент (таб. 3)<br>к2- исәпкә алынучы үсемлекнең торышын билгеләүче коэффициент, (таб. 4)<br>кц - үсемлекнең кыйммәте исәпкә алына торган коэффициент (таб. 5)<br>кд - үсемлекләрнең деградацияләнү коэффициенты (6 нчы таблица) |
| 4 | Табигый үләнчел үсемлекләр | У =8xк1xк2xкцxкд | У - зыян күләме<br>Б – алынган (юкка чыгарылган) табигый үләннәр үсә торган мәйдан<br>к1 - үсемлекләрнең әйләнә-тирә мохитне саклау үзлекләрен исәпкә ала торган коэффициент (таб. 3)<br>к2 – үсемлекнең торышын исәпкә ала торган коэффициент (таб. 4)<br>кц – үсемлекнең кыйммәтен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | исәпкә ала торган коэффициент (таб. 5)<br>кд - үсемлекләрнең деградацияләнү коэффициенты (таб. 6) |

*Яшел үсентеләргә зыян салганда зыян күләме, кулланучылар бәяләренең алдагы чорда товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) үзгәрүен исәпкә алучы коэффициент-дефляторны исәпкә алып, үзгәрергә тиеш.

1нче таблица

Агач үсемлекләренә китерелгән зыянның күләмен билгеләү өчен күрсәткечләр

| Җирдән 1,3м биеклектәге агачның диаметры (см) | Агачның биеклеге (Ъ), м | Биеклек буенча разряды | 1 берәмлек агач өчен алына торган үзагач күләме (V), куб. м | 1 куб. м үзагачның бәясе (Сд), сумнарда. | НДСтан (С) башка утырту һәм карау буенча башкарылган эшләрнең бәясе, сумнарда. | 1м биеклеккә кадәр булган үсентенең бәясе, сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Яфраклы агачлар | | | | | | |
| имән | | | | | | |
| 8 - 10 | 5 | III | 0,023 | 1200,0 | 2690,3 | 501,5 |
| 10-12 | 7 | | 0,043 | | | |
| 12-14 | 9 | | 0,072 | | | |
| 14т-16 | 1} | | 0,112 | | | |
| 16- 18 | 13 | | 0,164 | | | |
| 18 - 20 | 14 | | 0,219 | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 20 - 24 | 16 | | 0,29 | | | | |
| 24 - 28 | 18 | | 0,46 | | | | |
| 28 - 32 | 20 | | 0,68 | | | | |
| 32 - 36 | 21 | | 0,94 | | | | |
| 36 - 40 | 22 | | 1,23 | | | | |
| 40- 44 | 23 | | 1,56 | | | | |
| 44 - 48 | 26 | | 2,10 | | | | |
| 48 -52 | 27 | | 2,53 | | | | |
| 52 -56 | 27 | | 3,00 | | | | |
| 56 - 60 | 28 | | 3,52 | | | | |
| 60 - 64 | 28 | | 4,08 | | | | |
| 64 -68 | 28 | | 4,65 | | | | |
| 68 - 72 | 28 | | 5,27 | | | | |
| 72 - 76 | 28 | | 5,92 | | | | |
| 76 - 80 | 28 | | 6,61 | | | | |
| 80 - 84 | 28 | | 7,35 | | | | |
| 84 -88 | 28 | | 8,13 | | | | |
| 88 - 92 | 28 | | 8,92 | | | | |
| 92 - 96 | 29 | | 9,81 | | | | |
| 96 -100 | 29 | | 10,70 | | | | |
| 100 дән күбрәк | 29 | | 11,63 | | | | |

| |
|---|
| Юкә |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 -12 | 6 | III | 0,019 | 489,6 | 2690,3 | 501,5 |
| 12 - 16 | 9 | | 0,061 | | | |
| 16 - 20 | 12 | | 0,13 | | | |
| 20 - 24 | 14 | | 0,23 | | | |
| 24 - 28 | 15 | | 0,35 | | | |
| 28 - 32 | 17 | | 0,52 | | | |
| 32 - 36 | 18 | | 0,71 | | | |
| 36 - 40 | 19 | | 0,89 | | | |
| 40 - 44 | 19 | | 1,16 | | | |
| 44 - 48 | 20 | | 1,40 | | | |
| 48 -52 | 21 | | 1,69 | | | |
| 52 - 56 | 21 | | 2,00 | | | |
| 56 - 60 | 21 | | 2,34 | | | |
| 60 -64 | 22 | | 2,68 | | | |
| 64 -68 | 22 | | 2,98 | | | |
| 68 - 72 | 22 | | 3,042 | | | |
| 72дән күбрәк | 22 | | 3,85 | | | |
| Каен | | | | | | |
| 10 - 12 | 10 | II | 0,053 | 489,6 | 2690,3 | 501,5 |
| 12 - 14 | 11 | | 0,080 | | | |
| 14 - 16 | 12 | | 0,117 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 - 18 | 14 | | 0,164 | | | |
| 18 - 20 | 15 | | 0,218 | | | |
| 20 - 24 | 16 | | 0,28 | | | |
| 24 - 28 | 18 | | 0,43 | | | |
| 28 - 32 | 18 | | 0,61 | | | |
| 32 - 36 | 19 | | 0,83 | | | |
| 36 - 40 | 20 | | 1,09 | | | |
| 40 -44 | 21 | | 1,40 | | | |
| 44 -48 | 22 | | 1,76 | | | |
| 48 - 52 | 23 | | 2,17 | | | |
| 52дән күбрәк | 24 | | 2,64 | | | |
| | | | | | | |
| Усак, ольха, өрәңге, корычагач, карама, тополь | | | Тал һәм башкалар | | | |
| 10 - 12 | 11 | усак, зирек - II, калганнары - III | 0,057 | Усак- 489,6, калганнары - 200,6 | 2690,3 | 501,5 |
| 12 -14 | 13 | | 0,093 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 - 16 | 14 | | 0,133 | | | |
| 16 -18 | 15 | | 0,185 | | | |
| 18 - 20 | 16 | | 0,254 | | | |
| 20 - 24 | 17 | | 0,33 | | | |
| 24 - 28 | 19 | | 0,50 | | | |
| 28 -32 | 20 | | 0,71 | | | |
| 32 - 36 | 22 | | 0,99 | | | |
| 36 -40 | 23 | | 1,30 | | | |
| 40 - 44 | 23 | | 1,61 | | | |
| 44 - 48 | 24 | | 2,02 | | | |
| 48 - 52 | 25 | | 2,50 | | | |
| 52дән күбрәк | 25 | | 2,91 | | | |
| Ылыслы агачлар | | | | | | |
| Нарат | | | | | | |
| 8 - 10 | 8 | II | 0,027 | 920,4 | 2690,3 | 708,0 |
| 10 - 12 | 10 | | 0,049 | | | |
| 12 - 14 | 11 | | 0,076 | | | |
| 14 -16 | 14 | | 0,118 | | | |
| 16 - 18 | 15 | | 0,166 | | | |
| 18 - 20 | 16 | | 0,23 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 20 -24 | 18 | | 0,30 | | | |
| 24 - 28 | 20 | | 0,47 | | | |
| 28 - 32 | 22 | | 0,67 | | | |
| -32 - 36 | 23 | | 0,91 | | | |
| 36 -40 | 24 | | 1,17 | | | |
| 40 - 44 | 24 | | 1,47 | | | |
| 44 - 48 | 25 | | 1,81 | | | |
| 48 - 52 | 25 | | 2,17 | | | |
| 52 - 56 | 25 | | 2,55 | | | |
| 56 - 60 | 25 | | 2,97 | | | |
| 60 - 64 | 25 | II | 3,41 | 920,4 | 2690,3 | 708,0 |
| 64 -68 | 25 | | 3,88 | | | |
| 68 -72 | 26 | | 4,40 | | | |
| 72 -76 | 26 | | 4,93 | | | |
| 76 - 80 | 26 | | 5,48 | | | |
| 80нән күбрәк | 26 | | 6,09 | | | |
| Чыршы | | | | | | |
| 8 - 10 | 5 | II | 0,027 | 920,4 | 2690,3 | 708,0 |
| 10 -12 | 8 | | 0,049 | | | |
| 12 - 14 | 10 | | 0,076 | | | |
| 14 - 16 | 12 | | 0,118 | | | |
| 16 -18 | 14 | | 0,166 | | | |
| 18 -20 | 15 | | 0,23 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 20 - 24 | 17 | | 0,30 | | | |
| 24 - 28 | 19 | | 0,47 | | | |
| 28 - 32 | 21 | | 0,67 | | | |
| 32 - 36 | 23 | | 0,91 | | | |
| 36 -40 | 24 | | 1,17 | | | |
| 40- 44 | 25 | | 1,47 | | | |
| 44 - 48 | 26 | | 1,81 | | | |
| 48 -52 | 27 | | 2,17 | | | |
| 52 - 56 | 28 | | 2,55 | | | |
| 56 - 60 | 28 | | 2,97 | | | |
| 60 - 64 | 28 | | 3,41 | | | |
| 64 - 68 | 29 | | 3,88 | | | |
| 68дән күбрәк | 26 | | 4,40 | | | |
| Ак чыршы | | | | | | |
| 8 -10 | 5 | II | 0,018 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 10 - 12 | 7 | | 0,036 | | | |
| 12 - 14 | 8 | | 0,070 | | | |
| 14 - 16 | 10 | | 0,102 | | | |
| 16 - 18 | 12 | | 0,150 | | | |
| 18 - 20 | 13 | | 0,201 | | | |
| 20 - 24 | 15 | II | 0,27 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 24 -28 | 16 | | 0,65 | | | |
| 28 -32 | 19 | | 0,91 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 32 - 36 | 21 | | 1Д9 | | | |
| 36 - 40 | 22 | | 1,51 | | | |
| 40 - 44 | 24 | | 1,87 | | | |
| 44 - 48 | 26 | | 2,27 | | | |
| 48- 52 | 27 | | 2,70 | | | |
| 52 - 56 | 27 | | 3,11 | | | |
| 56 - 60 | 27 | | 3,75 | | | |
| 60 тан күбрәк | 27 | | 3,90 | | | |
| Карагай | | | | | | |
| 10- 12 | 11 | II | 0,068 | 920,4 | 2690,3 | 800,0 |
| 12 - 14 | 13 | | 0,105 | | | |
| 14 - 16 | 14 | | 0,150 | | | |
| 16 - 18 | 17 | | 0,209 | | | |
| 18 -20 | 18 | | 0,276 | | | |
| 20 - 24 | 19 | | 0,36 | | | |
| 24 - 28 | 21 | | 0,55 | | | |
| 28 - 32 | 24 | | 0,80 | | | |
| 32 -36 | 26 | | 1,08 | | | |
| 36- 40 | 27 | | 1,43 | | | |
| 40 - 44 | 28 | | 1,81 | | | |
| 44 -48 | 29 | | 2,23 | | | |
| 48 - 52 | 30 | | 2,68 | | | |
| 52дән | 30 | | 3,17 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| күбрәк | | | | | | |
| Эрбет | | | | | | |
| 10 - 12 | 10 | II | 0,053 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 12 - 14 | 11 | | 0,080 | | | |
| 14 - 16 | 12 | | 0,117 | | | |
| 16 - 18 | 14 | | 0,164 | | | |
| 18 -20 | 15 | | 0,218 | | | |
| 20 -24 | 16 | | 0,28 | | | |
| 24 - 28 | 18 | II | 0,43 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 28 - 32 | 18 | | 0,61 | | | |
| 32 - 36 | 19 | | 0,83 | | | |
| 36 -40 | 20 | | 1,09 | | | |
| 40 - 44 | 21 | | 1,40 | | | |
| 44 - 48 | 22 | | 1,76 | | | |
| 48 - 52 | 23 | | 2,17 | | | |
| 52дән артык | 24 | | 2,64 | - | | |

2нче таблица

Куаклы һәм үләнчел үсемлекләргә китерелгән зыянның күләмен билгеләү өчен күрсәткечләр

| N | Яшел үсентеләр | Үлчәү берәмлекләре | Утырту һәм карау буенча үткәрелгән эшләрнең НДС(С) тан башка бәясе | Утырту материалының бәясе |
|---|---|---|---|---|
| Яфраклы куаклыклар | | | | |
| 1 | Үсемлекләрдән торган койма | 1 пог.м. өчен сумнарда | 469,43 | 500,0 |
| 2 | Берәмләп утыртылучы үсентеләр | 1төп бәясе | 313,1 | 150,0 |
| Ылыслы куаклар | | | | |
| 1 | Берәмләп утыртылучы үсентеләр | 1төп бәясе | 461,6 | 600,0 |
| Лианалар | | | | |
| 1 | Берәмләп утыртылучы үсентеләр | 1төп бәясе | 313,1 | 150,0 |
| Газоннар | | | | |
| 1 | Болын үләннәре булган табигый үләнчел үсемлекләр | 1 кв. м өчен сумнарда | | |
| 2 | Чүп үләннәре булган табигый үләнчел үсемлекләр | 1 кв. м өчен сумнарда | | |
| 3 | Газоннар ( газон орлыклары чәчелгән газон) | 1 кв. м өчен сумнарда | 74,43 | 85,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Төргәкле газон | 1 кв. м өчен сумнарда | 200,0 ’ | 100,0 |
| Чәчәклекләр | | | | |
| 1 | Чәчәклекләр | 1 кв. м өчен сумнарда | 650,0 | Чәчәкле-декоратив үсемлекләр сортларына карап |

3 нче таблица

Үсемлекләрнең әйләнә-тирә мохитне саклау үзлекләрен исәпкә ала торган коэффициентның кыйммәте (kl)

| | Кыйммәт kl |
|---|---|
| Гомуми файдаланылыштагы үсемлекләр | 2 |
| Чикләнгән файдаланылыштагы үсемлекләр | 1,5 |
| Махсус файдаланылыштагы үсемлекләр | 1 |

4нче таблица

Үсемлекләрнең торышын исәпкә ала торган коэффициентның кыйммәте (к2)

| Үсемлекнең торышы | Үсемлекләрнең торышы дәрәҗәсе яфраклар торышыннан чыгып билгеләнә | Кыйммәт к2 |
|---|---|---|
| Яхшы ( сәламәт) I | 100% яфрак | 2 |
| Уртача көчсезләнгән 11 | 90-70% яфрак | 1,5 |

| | | |
|---|---|---|
| Көчле көчсезләнгән III | 60-40% яфрак | 1 |
| Кибеп баручы IV | 30-20% яфрак | 0,5 |
| Үлә баручы V | 20-10% яфрак | 0,1 |
| Үле VI | Яфраклары юк | 0 |

5нче таблица

Үсемлекләрнең кыйммәтен исәпкә алучы коэффициент(кц)

| Группа ценности | Виды деревьев и кустарников | кыйммәте кц |
|---|---|---|
| 1нче төркем ( аеруча кыйммәтле) | - ылыслы, мәңгеяшел агачларның барлык төрләре, шул исәптән: кедр, нарат, чыршы, чыршы, карагай;<br>- яфраклы агачларның берничә төре, шул исәптән: имән, корычагач, зирек, карама, элмә | 1,5 |
| 2нче төркем ( кыйммәтле) | ылыслы куакларның барлык төрләре;<br>- яфраклы агачларның кайбер төрләре, шул исәптән: юкә, каен, өрәңге | 1,2 |
| 3нче төркем ( кыйммәте түбән) | Калган башка төр агачлар һәм яфраклы куаклар | 1 |

III Киселә торган яшел үсентеләр өчен акчалар кертү һәм тоту тәртибе

3.1. Киселә торган яшел үсентеләр өчен акчалар түбәндәгеләр хисабына җыела:

кисеәлә торган яшел үсентеләр өчен түләүләр;

яшел үсентеләрне законсыз кисү аркасында китерелгән зыянны каплау өчен түләнгән акчалардан (компенсацияләү);

яшел үсентеләргә зыян китергән өчен административ хокук бозулар турындагы законнар нигезендә алына торган штрафлар;

яшел үсентеләрне саклау һәм үстерү максатларына гражданнарның һәм юридик затларның, шул исәптән чит илләрнең ирекле кертемнәреннән;

башка чыганаклардан керемнәр.

3.2. Яшел үсентеләрне законсыз рәвештә зарарлаганда яисә юкка чыгарганда зыянны каплаудан килгән акчалар, штрафлар билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр нигезендә яисә суд карары буенча кертелә.

Методикада күрсәтелгән түләүләрнең күләме юкка чыгарылган үсемлек өчен 5 мәртәбә һәм һәр зарарланган үсемлек өчен 1/2 мәртәбә билгеләнә.

3.3. Яшел үсентеләрне законсыз юкка чыгарган яки зарарлаган өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан кертелгән торгызу бәясе Тәбәрлеавыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына керә һәм төзекләндерү маддәсе буенча тотыла.

Юкка чыгарылган яки зарарланган яшел үсентеләр өчен алынган акчалар яшел үсентеләрне торгызуга, шул исәптән түбәндәге эшләрне финанслауга тотыла:

- агач һәм куак үсентеләрен казып алуны, автотранспортка төяүне һәм бушатуны, агач төпләрен төрүне, үсенте һәм орлык бәяләрен, яшелләндерү өчен алына торган бәягә түләүне дә кертеп, утырту материалын сатып алуга (әзерләүгә) һәм илтеп җиткерүгә;

- җирне планлаштыруны, сөрүне, дисклауны, туфракны фреза белән йомшартуны, тырмалауны, җирне тигезләүне дә кертеп, газон төзүгә, агач һәм куаклар утырту өчен әзерләүгә;

- агач һәм куаклар утырту өчен чокырлар һәм канаулар (траншеялар) казуга;

- агачлар, куаклар утыртканда һәм газон ясаганда туфракны 25%, 50% яки 100% ка алыштыруга;

- биоматлар, агач рәшәткәләр, кием-салым, кәс бәясен дә кертеп, авыш җирләрне ныгытуга;

- утырту урыннарын әзерләгәндә һәм газон ясаганда туфракка органик һәм минераль ашламалар кертүгә;

- агач һәм куакларны әзер чокырларга һәм траншеяләргә утыртуга;

- үлән орлыкларын чәчүгә (гидрочәчүне дә кертеп), кәс салуга;

- вертикаль яшелләндерү эшләренә;

- газон үләннәренең орлыкларын өстәп чәчүгә;

- яшелләндерүнең гомуми файдалануда гамәлдә булган объектларын реконструкцияләүгә;

- яшел үсентеләр утырту һәм күчереп утырту өчен махсус техника сатып алуга;

- чүп-чарны төяү һәм чыгаругә;

- территорияне әзерләү эшләре (корыган агачлар кисү, агач төпләрен чыгару, территорияне планлаштыру, су сибү суүткәргечен урнаштыру, юл-сукмак челтәрен булдыру, яктырту, кече архитектура формаларын урнаштыру һ.б.) төзелеш бәясенең 70% ыннан да артык булмаган күләмдә компенсацион яшелләндерү өчен;

- чәчәклекләр төзүгә;

- паркларны һәм скверларны төзекләндерүгә.

Акчаларны компенсацион яшелләндерү чараларыннан башка максатларда файдалану тыела.